**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ИСКЕ ЧАЛЛЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

# КАРАР

**«25» ноябрь 2024 ел** **№ 89**

**Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Иске Чаллы авыл җирлеге Советының "Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Иске Чаллы авыл җирлеге" муниципаль берәмлегендә бюджет процессы турында Нигезләмәне раслау хакында " 2019 елның 15 ноябрендәге 111 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы, «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Иске Чаллы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Иске Чаллы авыл җирлеге Советы **КАРАР ИТТЕ:**

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Иске Чаллы авыл җирлеге Советының 15.11.2019 №111 карары белән расланган «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Иске Чаллы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә бюджет процессы турында Нигезләмәнең 1нче кушымтасына (Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Иске Чаллы авыл җирлеге Советы тарафыннан 21.02.2020 № 121, 07.09.2020 № 128, 08.12.2023 № 69, 26.03.2024 № кертелгән үзгәрешләр һәм өстәмәләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- Нигезләмәнең 13 статьясындагы 2 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:

«2. Дәүләт (муниципаль) контрактлары дәүләт (муниципаль) ихтыяҗларын тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алулар план-графигы нигезендә, дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алулар

өлкәсендә контракт системасы турында Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә төзелгән һәм расланган (Россия Федерациясе законнары нигезендә мондый план-графикка кертелүгә тиешле сатып алулар булмаган очраклардан тыш) төзелә.), һәм бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә түләнәләр, Россия Федерациясе Бюджет кодексының 72 статьясындагы 3 пунктында билгеләнгән очраклардан тыш.»

Рәислек итүче,Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Иске Чаллы авыл җирлеге Советы депутаты Г.В. Герасимов